| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯЛАУР АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Ялаур ав. КАРАР

«14» октябрь 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Октябрина поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Ялаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 27 октябрендә 14 сәг.00 минутка Октябрина п., Садовая урамы 5нче йорт адресы буенча Садовая ур., 1-38 йортта яшәүчеләр, Полевая урамы 2-29 йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын уздыру өчен Октябрин бистәсендә яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

3. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Октябрина бистәсендә яшәүче гражданнар өчен тәэмин ителә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Октябрина авылының мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Ялаур авыл җирлеге башлыгы П.В.Сандиряков